ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2017 елның 27 феврале**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 378**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 20 гыйнварындагы 45 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 145 статьясындагы икенче өлеше, 349.5 статьясы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләр» 9 бүлеген, «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениеләренең физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләр» 8 бүлеген түбәндәге эчтәлекле текст белән тулыландырырга:

«2017 елның 1 гыйнварыннан җитәкчеләрнең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларның уртача айлык хезмәт хакының һәм әлеге предприятиеләр хезмәткәрләренең уртача айлык хезмәт хакының (җитәкчеләрнең, урынбасарларның һәм баш бухгалтерларның хезмәт хакын исәпкә алмыйча) 1 дән 8 гә кадәр булган нисбәтенең иң чик дәрәҗәсен билгеләргә.

Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының уртача айлык хезмәт хакы турында календарь ел өчен исәпләнә торган мәгълүмат Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, хисап елыннан соң киләсе елның 31 мартыннан да соңга калмыйча, урнаштырылырга һәм «Интернет» мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге барлык кулланучылар өчен мөмкин булган формада бәян ителергә тиеш.

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиешле булган мәгълүмат составында учреждениенең тулы исеме, вазыйфасы, җитәкчеләрнең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме күрсәтелә.

Югарыда каралган мәгълүмат составында яшәү урынын, почта адресын, телефонны һәм җитәкчеләрнең, урынбасарларның һәм баш бухгалтерларның башка шәхси коммуникация чараларын билгеләргә мөмкинлек бирүче мәгълүматны, шулай ук дәүләт серенә яки конфиденциаль характердагы мәгълүматны күрсәтү тыела.

Муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре айлык хезмәт хакы турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә хисап елыннан соң килүче елның 20 мартыннан да соңга калмыйча җибәрергә тиеш.»

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге Тәртиптә каралган мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин